ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

16 июнь 2026 ел №47

Норлат авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында 2026 елның 02 июнь 42 номерлы Совет карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Техник хатаны бетерү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Норлат авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Норлат авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы 2026 елның 02 июнь 42 номерлы Совет карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 10 статьяның 6 пунктында «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «Норлат авыл җирлеге Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 12 статьяның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Авыл җирлеге Советы сессияләрендә катнаша алмаганда, депутат, бер көннән дә соңга калмыйча, бу хакта авыл җирлеге башлыгына хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук торак пунктның мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Заволжье» ЦКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (администрациясе бинасы) бастырып чыгарырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.М.Саттаров